# УТЫ СҮНГӘН ҖӘҺӘННӘМ

## I

...Төн. Сәгать ике. Мин зур, караңгы өйнең аулак бүлмәсендә ялгызым утырам. Баярак лампы яна иде. Хыялның чәчәкләнүенә* манигъ булганга[1], аны сүндердем. Бүлмәмнең карт агачлар белән тулган зур бакчага караган бердәнбер тәрәзәсе бар. Мин шуның яңагына артым белән терәлеп, күзләремне тышның куе һәм шомлы караңгылыгына юнәлдергәнем хәлдә, төннең тынлыгына күмелеп тик кенә утырам. Берничә сәгать үтә. Өйдә һичбер тавыш-тын юк. Мин һаман шул урында, шул хәлдә ялгызмын; тик хыялым гына каршымда.

Баярак күк күкри, куәтле яшен яшьни, каты җил дә исеп куя, ара-тирә калын, катлаулы болыт артыннан тулган ай карап, бөтен дөньяга матур гына бер елмая да тагы югала иде. Инде бары да тынды. Ай да яңадан күренмәслек булып катлаулы болыт артына ышыкланды. Дөнья тагын да тирән, куе караңгылык эченә күмелде. Күк йөзе тәмам капланып, яңгыр коярга тотына. Ул башта чиләктән актарылгандай кызу яуса да, бераздан әкренәйде, — ул инде вак, тигез һәм туктаусыз. Үзе һәр йирдә дә шулай булыр. Хәзер дөньяның һәр ягында шундый вак һәм тигез булып яңгыр явадыр кебек тоела.

Хатыным күптән йоклый. Ул миңа берничә тапкыр:

— Садыйк, сиңа ни булды, ят инде! — дип караса да, мин аны тыңламадым.

Ул мине көтә-көтә аптырагач:

— Җә инде, Садыйк! Иртәгә иртә үк базарга барасың да бар ич! — дип, тагы бер кыстап карады, ләкин мин һаман утыра бирәм.

Йокы каядыр качкан. Шул тигез, вак һәм туктаусыз коелган яңгырны озак, бик озак тыңлыйсым килә; йөрәгемне кайнаткан, җанымны дулкынлаткан бүгенге вакыйга уңае белән очсыз-кырыйсыз хыялга ихтыярсыз тартылып барам.*

Мин гомумән төнге яңгырны бик яратам. Хәзерге кебек салмак, ләкин еш һәм тигез генә, җиңгел генә шыбырдап торса, бөтен җаным белән бирелә́м. Аның сак кына, тын һәм акрын гына коюы мине дә башка вакытларда белми торган акрын шатлыкларгамы, тын гына кайгыгамы —

---

*1911 елгы вариантта бу сүз *табигый агымына* дип бирелгән.

[1]*Манигъ* — киртә, тоткарлык.

*1911 елгы басмада бу абзац түбәндәгечә бирелгән: *Никтер йокы килми. Шул тигез, вак һәм туктаусыз коелган яңгырны озак, бик озак тыңлыйсы; йөрәгемне кайнаткан, җанымны дулкынлаткан “теге эш” уңае белән очсыз-кырыйсыз хыялга чумасы килә.*

белмим, нәрсәгә — алып китә.[**] Рухымның әллә кайчаннан бирле эзләп тә таба алмый йөргән теләге шул вакытта, шул караңгы төндә өзлексез коелган вак яңгырның шыбырдавы астында табылгандай тоела. Шуның тәэсирендә бай вә киң бер хыялга чумып, барын да онытам. Хәятның көндезге аек һәм шау-шулы чагында сизелмәгән, илтифат ителмәгән нәрсәләр бу вакытта кояш кебек ачык күреләә. Бу вакытның хыялында да аерым бер тәм, бөтенләй башка булган бер ямь була; моны хис кыйлмаган адәмнәр зур бер сәгадәттән мәхрүмнәрдер дип уйлыйсың, аларны кызганасың...[***]

Бу көн, хосусый бүгенге көн исә рухымы бик тирәннән дулкынландырган башка бер вакыйга да бар. Ахры, шул хыялны гадәттәгедән артык җанландырды, йөрәкне, тынган, йоклаган йөрәкне кузгатты.[*]

**II**

Иртәнчәк хатыным белән тәмләп кенә чәй эчеп утыра идек. Арада кызык бер әңгәмә бара: ул, яшь чагында үзенә гашыйк булып, «саргайдым, үләм» дип йөргән бер егетнең вакыйгаларын сөйли башлаганга, чәемездә аерым бер тәм булачак иде. Күп булса берәр чынаяк эчкәнмездер, кинәт бер кыңгырау тавышы ишетелде: ул авылның югары ягыннан безгә таба килә иде. Тиз арада безнең турыга җитеп, кемгәдер туктагандай булды. Һәм шул минутта ук берничә малай, күзләрен акайтып,безнең өйгә чабып керделәр дә, берсеннән-берсе ашыгып:

— Мулла абзый, мулла абзый!! Сезгә зимски нәчәлник[1+] килде, — дип акырыштылар.

Без каушый калдык. Минем мулла булганыма ике генә ел, земский белән таныш та түгелмен; башкача да йомыш юк кебек, — ник килер икән?

Өстемә бишмәтне кидем дә «зимски»ны каршы алырга дип чыктым. Яңа тарантаска җигелгән ике яхшы кара атны, әйбәт киемле кучерны, арбага ята төшеп утырган, бөтенләй яурупача[1] киенгән алтын күзлекле русны күреп, башта эчем шу итеп китте.[**] Ләкин бер секундта эш бөтенләй үзгәрде. Ни күзем белән күрим — көләргә дә, кычкырырга да белмәдем... Земский дип каршыларга чыккан адәмем бөтенләй башка кеше булып, үземнең яшьлек

---

[**]1911 елгы басмада бу җөмлә: *Аның сак кына, тын һәм акрын гына коюы мине дә бүтән чакларда булмый торган тын гына кайгыгамы — белмим, нәрсәгә — алып китә.*

[***]1911 елгы басмада бу җөмлә: *Бу вакытның хыялында да аерым бер тәм, бөтенләй башка булган бер ямь була; шөйлә ки боны хис кыйлмаган адәмнәр зур бер сәгадәттән мәхрүм кеби тоелалар.*

[*]1911 елгы басмада бу җөмлә урынында түбәндәге җөмлә булган: *Шунлыктан хыялның дәхи төрлерәк эшләп, тәэсирнең дәхи көчлерәк булуы да табигый.*

[1] *Яурупача* – европача.

[**]1911 елгы басмада бу җөмлә: *Кыйммәтле тарантаска җигелгән ике яхшы кара атны, ямщиклар кыяфәтендәге кучерны, һәм түрдә тәмам франт уларак киенгән алтын күзлекле бер русны күреп, башта эчем шу итеп китте.*

елларымның күбен бергә уздырган бер танышым булып чыкты.[***]

**III**

Мин мәдрәсәдә чагымда яхшы, бай тора, бай балаларына, зур хәзрәтләрнең мәхдүмнәренә хас булган дәресханәдә байларча гына яши идем. Өйдән килгән азыкның, төрле ашамлыкларның иге-чиге булмый иде. Байлыгым шундый шәп булып, дәрәҗә дә зарарсыз булганга, мин, әлбәттә, үзем самавыр куеп, пешеренеп йөрмәдем. Минем мондый эшләрне бер ярлы ятим шәкерт үти, ул бичара акча алмый, тик тамак җалына эшли иде.

Бу шәкертнең йөзе күңелсез[*], өсте-башы һәрвакыт ертык һәм керле булганга, сабакка да чамалы күрелгәнгә, аны бер дә санга сукмыйлар иде. Ул безнең мәдрәсәдә байтак еллар торды, аның иптәшләренең дәрәҗә һәм урыннары югары ашты исә дә, аның урыны мич буеннан күчмәде. Ул үзе дә бик югарылыкны теләми иде бугай. Аны һәммәсе кимсетәләр, яратмыйлар, җәберлиләр, теләгәнчә мыскыллыйлар, исеме белән дәшмичә, башы зурлыктан «Тубал» дип кенә йөртәләр иде.

Бу Тубал тыштан караганда бик гади, бик садә, бераз тилемсәрәк кебек күренсә дә, аның эчендә тышына башка булган бер дөнья бар шикелле тоела, аның күзендә кайбер вакыт куркыныч галәмәтләр ялтырап китә иде. Һәм нәтиҗәдә шундый бер халәт аңлашылды да.

Ул бер елны үзгәреп китеп, һәрвакыт сагышка батып йөри башлады. Башка вакытларда беркая чыкмый торган Тубал, бу елның рамазаны кергәч, икешәр көн югалып торгалады. Үзе һаман уйлана иде. Шәкертләр анардан көлеп:

— Тубалга дәрт тулган бу ел! — диләр иде.

Уразаның егерме җидесендә кадер кичәсе булды. Бөтен шәкерт тәравихка[1] китте. Тубал исә, «авырыйм» дип, мәдрәсәдә калган.

Ышанырсыңмы? — Кайтсам, Тубалдан җилләр исә, әйберләре дә күренми. Белгән-күргән дә юк. Шул юктан юк. Шулай итеп Тубалымыз югалды. Яңа малай тапканчы миңа да үзем өчен самавыр куеп йөрергә тугры килде.

Үзеннән соң аның хакында төрле хәбәрләр чыгып, кайсылар: «Хаҗилар белән Мәккәгә киткән имеш», — ди. Кайберәүләр: «Сартларга[2] ияреп Бохарага качкан имеш», — дип сөйләнсәләр дә, аныгын белә алмадылар.

Мин үзем тагы малай таптым; шул көннән аны исемнән чыгарып, инде

---

[***]1911 елгы басмада бу җөмлә: *Земский дип каршыларга чыккан адәмем бөтенләй икенче булып чыкты вә икенче төрле тәэсир бирде.*

[*]1911 елгы басмада *йөзе күңелсез* сүзләре – *кыяфәте сөйкемсез* дип бирелгән.
[1]*Тәравихка* — ураза аенда кич белән укыла торган өстәмә намазга.
[2]*Сартларга* — үзбәк халкын Октябрьгә кадәр мыскыллап шулай дип атаганнар.

исемен дә оныткан идем.

Бу көн, земский каршысына дип каушый-каушый чыгып, каршымда теге алтын күзлекле франт адәм эчендә шул Тубалны таныгач, шаша калдым. Төшме, дим. Юк, ул өн иде. Дөнья күрмәгән авыл малаеның күзенә земский начальник булып күренерлек рәвештә киенеп, кыңгырау илә миңа килеп төшкән адәм — чынлап та шул Тубал, шул качандыр тамагы ач, өсте ялангач, миңа тамак ялына самавыр куйган малай иде. Кинәт очрауда шашарлык та бар. Ул уйга килмәслек дәрәҗәдә үзгәргән. Зиһендә сакланган сурәт белән хәзер каршыңда торган бу егет арасында мөнәсәбәт табу бик читен. Аңа хәзер Тубал дигән исем ятмый да, аны Тубал дип атау, борын табигый күренсә дә, инде бер дә килми дә, килешми дә, мөнәсәбәтсез дә шикелле. Ул хәзер тышкы ягы белән халыкның «зур түрәсе», ул европеец, ул мөкәммәл[1] франт... вәссәлам.

## IV

Аның чын исеме Гыйльман икән, фамилиям — Каһиров ди.[*] Ул миндә кичкә чаклы торып, кояш баер алдыннан гына китте. Кыш көне шәһәрдә укуда булып, җәйлигә безнең күрше авылдагы бер байның балаларын укытырга килә. Миңа шунда барышлый кергән. Без очрашуымызга бик шатландык; ул бигрәк тә. Аның белән күп һәм иркен сөйләштек. Бигрәк ул сөйләде. Минем исем китте дә торды. Шуны кара: ул үзенең әллә нәрсәсе белән мине баса, тыгызландыра, тартындыра шикелле тоелып китә. Адәм үзгәрсә үзгәрә икән, Ходаем! Ул бөтенләй икенче кеше булган — ул ачык, ул мәдәни, ул белемле. Аның башыннан әллә ниләр кичкән. Ул, безнең мәдрәсәдән киткәч, казакъ хаҗиларына ияреп Мәккәгә барган, аннан, хаҗ кылмыйча ук, кире Истамбулга килеп, мәктәптә берничә ел укыган да, Русиягә кайтып, хак белән мөгаллимлек кылган. Соңра фикере үзгәреп, мөгаллимлектән җыйган акчасы белән русча укырга тотынган. Шуннан бирле һаман укыган, әле дә укый.[*]

Безнең аерылышканга тугызынчы ел. Ул шушы гомердә төрле дәверләр кичереп, урта мәктәпләрдәге хәтле укып та өлгергән. Мәктәп программыннан тыш та бик күп нәрсә күргән. Ни турында гына сүз чыкмасын, мине күмә дә ташлый. Мин күп урында аның сүзен аңлап йитә алмый интегәм. Мин үземнең бернәрсә дә белмәүне, минем һәр сүзем коры «авыз фәлсәфәсе» генә

---

[1]*Мөкәммәл* — чын-чыннан.

[*]1920 елгы басмада Гыйльман Каһиров, 1911 елгы басмада Гыйльман дип бирелгән. 1911 елгы басмада бу җөмлә түбәндәгечә: *Инде чын исеме белән атыйк: Гыйльман.*

[*]1911 елгы басмада бу урында түбәндәге өзек бар: *Алда да укыячак. Ул бу хакта бик кыска гына әйтеп: – "Мин мещаннар тормышын яратмыйм, мин кабергәчә укыйм!" – ди. Укырга кирәк булган акчаны кайдан табуы хакында сорагач: – Тырышсаң, табыла ул! дип, зур бер ышаныч илә генә әйтеп куя.*

идекен бүген, Каһиров белән сөйләшкәннән соң, ачык белдем. Моның өстенә ул хәзер һавадагы кош дәрәҗәсендә ирекле, дүрт ягы кыйбла, кая китсә дә, ни кылса да, иреге бар. Укуы, белүе һәм азатлыгы гына тагы бер хәл: ул алдагы көннәренә бөтенләй икенче төрле карый.[**] Ул: «Әле мин хәятны башламаганмын, мин әле аңа хәзерләнәм генә, чын хәят алда булачак», — ди. Ул ерак, югары һәм алга омтыла. Ул күзен күккә, гарешкә терәп, хәяттан алуы мөмкин булган насыйбына ирешергә үкереп бара.

Ничек тә истикъбален[1], үткәне белән хәзергесен дә алда һәм гали күрә, шуны өмит итә, һәм хакы да бар.

**V**

Адәмнәр табигатьләре, куәтләре буенча[*] берничәгә бүленәләр: бертөрлесе үзенең тимер кулы, куәтле ирадәсе[2] белән әхвальне[3] үзе теләгән якка бора — болар хәятның чыннан иясе, идарә кылучысы булалар. Икенче бүлеге исә ирадә куәтләре аз булган адәмнәр булып, алар әхвальнең агымына буйсынырга мәҗбүрләр, алар хәятның үз язмышларына хаким түгел, бәлки аның колы була[**]. Мин икенче бүлектәнмен ахрысы; шундый бер мәсьәлә хаккында сүз чыкканда, миңа бер иптәшем: «Син тышкы тәэсиратка һәрвакыт җиңеләсең, син гакыл белән, ноткың белән[4] түгел, миең белән эш кыласың. Син әхваль һәм хиссият колы, син — әхваль агымына ятмый кала алмыйсың!» — дигән иде. Бу вакытта мин, бу сүзгә каршы барып, сүздә аны рәд кылган[5], янымдагы ишекнең тоткасыннан тотып: «Син яңлышасың, син минем тимер ирадәле икәнемне белмисең, тоткасыннан тоткан менә шул ишекне теләгән якка борып йөртә алган шикелле, тормыш агымнарын үзем теләгән якка шулай бора алам», — дигән идем. Һәм шул игътикадта[6] идем. Бүген исә яңлышканымны ачык белдем, үземнең «әхваль агымына кол» идекемне бүген сиздем. Моңа да Каһиров белән очрашу сәбәп булды.

Хәзерге минутта рухымның, ни дәрәҗәдә дулкынланганын әйтеп йиткерергә сүз таба алмыйм. Гыйльманның килеп китүе миңа чыннан да бик авыр тәэсир итте. Ул миңа тормышымның ни хәлдә икәнен кәшеф иттереп[7], йөрәгемне — тынган, йоклаган йөрәгемне бөтен урыны белән кузгатты. Мин,

---

[**]1911 елгы басмада бу җөмлә түбәндәгечә яңгырый: *Укуы, белүе һәм азатлыгы гына тагы бер хәл: ул алдагы көннәренә бөтенләй икенче вә миңа караганда бөтенләй башкача карый.*

[1]*Истикъбален* — киләчәген.

[*]1911 елгы басмада *табигатьләре, куәтләре буенча* сүзләре – *куәт җәһәтенчә* дип бирелгән.

[2]*Ирадәсе* — ихтыяры.

[3]*Әхвальне* — хәлләрне.

[**]1911 елгы басмада бу җөмлә: *Икенче бүлеге исә ирадә куәтләре аз булган адәмнәр булып, алар әхвальнең агымына буйсынырга мәҗбүрләр, алар тормышның иясе, мөдире түгел, бәлки бәндәсе булалар.*

[4]*Ноткың* – сөйләмең.

[5]*Рәд кылган* — кире каккан.

[6]*Шул игътикадта* — шулай дип ышана.

[7]*Кәшеф иттереп* — ачыш ясап.

чынлап та, сискәнеп киткәндәй булдым. Гүя, әллә ничә еллар мәрткә китеп торып, яңа терелдем; яисә исереп, яңа айныдым да, хәзерге торган халәтемне аңлап, шаша калдым. Исрафил өченче «сур[1]»ны өргәч[2+], адәмнәр каберләреннән кубарылып чыгарылалар да туфрак өстендә ни кылырга белми вә ни хәлдә идекләрен аңламый хәйран булып утырырлар, ди. Мин дә шулай булдым. Мин чынлап та әхваль һәм язмыш[*] колы икәнмен. Бик гади, бик иттифакый[2] бер эш мине дер селкетте, бөтенләй икенче төрле тойгылар эченә салды.[**] Мин хәйрәттәмен[3]: мин кем булырга уйлый идем, минем идеалым нәрсә иде? Ә вакыйгдә[4] кем булып калганмын, хәзер кеммен? — Менә шушы ике сөальнең җаваплары арасында йир белән күк арасы чаклы аерма бар, — чыннан да, әнә шул мине хәзер изтираб[5] дулкынында әйләндерә.

Чыннан да, мин — кем идем, мин кем булырга уйлый идем? Үзеңне тәгъйин итү[6] авыр, шулай да әйтә алам: мин бик бай хыяллы, хәяттан бик күп нәрсә өмит итүче адәмнәрдән бере идем. Төрле мәдрәсәләрдә укыган соң үзеңне үзгәртү, мәдәниләшү, дөнья фәннәре тәхсил итеп[7], иҗтимагый эшләрнең бере артыннан йөри торган бер халык хезмәтчесе булу — минем баш теләгем иде[***]. Бүгенге кебек исемдә: үзем ач булам, бер тиенгә аптырап, каңгырып йөрим; шулай да рух куәтле, йөрәк таза, хәзерге ачлыкны, газапны алдагы өмит белән җуя торган идем. Мин ул чакта алдымда бик күп, бик олуг эшләр, мәртәбәләр барлыгына ышана, шуңа омтыла идем. Үземне, ничек тә, дөньяга килгәнгә оялмаслык бер рәвештә фараз кыла идем.

Була вакытлар: ачсың, эчең тырный, бер кабым икмәккә мохтаҗсың[*], ә шул вакыт хыялың, барлык авырлыкны оныттырып, алдагы нәрсәләр белән җуата. Лампыны басып куясың да киләчәкне уйларга тотынасың. Ул төрлечә күренә: кайбер халык өчен бик зур эшләр кыла торган бер фидаи буласың; сине тотып асалар, ләкин син үлемнең күзенә көлеп кенә карыйсың. Син мәсгудсең, чөнки фидаилек шәрәфенә ирешкәнсең; яки халык өчен утыз еллап зинданда ятып, сакалың агаргач чыгарылып, халык тарафыннан зур

---

[1]*Сур* — быргы.

[*]1911 елгы басмада *язмыш* сүзе урынына *тәсадиф* сүзе килә.

[2]*Иттифакый* — очраклы.

[**]1911 елгы басмада бу урында түбәндәге җөмлә бар: *Дәр вакыйг мин шаша калдым.*

[3]*Хәйрәттәмен* — аптыраштамын.

[4]*Вакыйгдә* — чынлыкта.

[5]*Изтираб* — борчылу.

[6]*Үзеңне тәгъйин итү* — кем икәнеңне билгеләү.

[7]*Тәхсил итеп* — өйрәнеп.

[***]1911 елгы басмада бу җөмлә түбәндәгечә бирелгән: *Төрле мәдрәсәләрдә йөреп соңра үзеңне үзгәртү, дөнья фәннәре укып, иҗтимагый эшләрнең бере артыннан йөри торган зыялы вә мәдәни бер адәм булу — минем баш теләгем иде.*

[*]1911 елгы басмада *бер кабым икмәккә мохтаҗсың* сүзләре урынында *ашарга акчаң юк* сүзләре килә.

ихтирам илә каршы алынасың. Син мәсгудсең, ак сакалың буйлап шатлык яшьләре ага — чөнки гомерең идеалыңа ирешү юлында үткән. Кайбер вакыт үзеңне һәркачан җәмәгать файдасын гына уйлый торган бер доктор яки атаклы бер галим ясап, яки халыкның мәдәни күтәрелүе юлында иң зур урын тоткан бер адәм итеп уйлыйсың.[**] Ләкин һичбер тәкъдирдә, яңлыш кына да үзеңнең бер караңгы авылга мулла булып, фидия[1] ашап гомер итүең уйланмый, истикъбальдә бу көн килүе һичбер ихтимал тотылмый; ул ихтимал юк, бөтенләй үк юк.

Менә мин хыялым белән шундый идем; минем күзләрем тугры гарешкә[2] карый, минем күңелем үземчә мөкаддәс дип, гали дип таныган идеалыма гына табына, шуңа гына сәҗдә кыла иде. Ләкин мин йомшак һәм куәтсез кеше икәнмен. Минем хаккымда теге иптәшемнең сүзләре бар да тугры булган. Мин, тормышны, әхвальне үзем теләгән якка борырлык куәтем бар дип уйласам да, вакыйгдә әхвальнең агымына кол икәнмен. Тормыш тәэсир иткән дә, минем фикерем ачылып, теге «мөкаддәс идеал»га табынырлык бер мәртәбәгә килгән. Икенче яктан дулкын чыккан, әхваль алышынган, шуның белән бергә мин дә агымга каршы бара алмаганмын, җиңелгәнмен. Тоткасыннан тотып, ишекне уңга да, сулга да борган кебек, үзем теләгән якка борырга уйлаган хәят куәтле дулкыны илә элеп алган да, диңгезгә ташланган бер җомычка рәвешендә уйнатып йөртеп, ниһаять, караңгы бер авылга, томан эченә китереп ташлаган, шунда мулла ясаган. Мин хәзер читек кунычы кайтарылган бер мулла: җеназа укыйм, фидия алам, бәлеш ашыйм. Барлыгы шул — менә теге идеалдан, теге хыялдан шул көнге хәлгә төшкәнмен. Теге вакытта моны уйлау түгел, зиһенемә дә китерми идем. Хәятта һәрнәрсә акрын бара, сизелмәстән килә, — мин дә шулай булдым. Минем теге юлдан чыгуым, авышуым бар да табигый, бар да сәбәбе белән булды. Ни булса булган, кителгән, бетелгән. Мин моны үзем тоймый, ачык иттереп уйлый алмый идем. Бүген Каһиров килеп, аның нәкъ шул мин уйлаган юлда, шул йолдызга таба баруын, миннән күп түбән йирдән күтәрелеп, һаман егылмавын күргәч кенә, бөтен дәһшәте белән ул хыяллар уянып, җанланып чыктылар. Аның армый-талмыйшул идеалга омтылуын күрү миңа ачык күрсәтте ки: мин хәят юлында бик зур яңлышлыклар эшләгәнмен; яки миндә куәт булмаган. Ни дә булса булган, мин, күктән, гарештән егылып, әллә кая төпкә, астка, коточкыч түбәнгә киткәнмен. Бу

---

[**]1911 елгы басмада бу җөмлә түбәндәгечә яңгырый: *Кайбер вакыт үзеңне һәркачан гомум файдасын гына уйлый торган бер доктор яки атаклы бер адвокат ясап, яки татар халкының тәркыять мәдәния хәрәкәте юлында иң зур урын тоткан бер адәм итеп уйлыйсың.*

[1]*Фидия* — үлгән кешенең гөнаһсын йолып алу өчен бирелгән мал.
[2]*Гарешкә* — күккә.

бәлки ят, яки яңлыш тоелыр. Ни булса булсын, ләкин мин хәзерге минутта шуны хис кылам. Үзенә бу хәл вакыйг булмаган адәмнәр моны табигый түгел диярләр. Бәлки шулайдыр, көннең шау-шулы, аек чагымда бәлки үземә дә башкачарак тоелыр; ләкин тын, караңгы төндә бу бөтен дәһшәте белән каршы килеп баса да, рухны ни дип тә тәгъбир итеп булмый торган бер изтираб каплый, йөрәкне тын, ләкин гаять көчле бер әрнү баса. Хәят мәңгелеккә җимерелгән, алдагы көнең хәзергедән дә күп түбән, күп караңгы булыр шикелле тоела, шул тойгы йөрәгеңне яра*.

**VI**

Салмак кына, тигез һәм әкрен генә шыбырдап торган яңгырны тыңлый торгач, мин бик әз генә шагыйрь дә, бик әз генә фәйләсуф та булып китәм бугай. Шул изтираблар, әрнүләр эчендә күңелгә илһами бер уй килә. Уйлыйм: ничек, дим, табигатьтә хозур. Бүген көн буена аяз булды. Күк йөзе киң һәм ачык булып, кояш туры, сөеп карый иде, дөнья рәхәтләнде, көлде.

Бу — табигатьтә уртак бәхет иде, ләкин бу бәхет озакка бармады, кичкә таба болыт чыкты. Дөньяны яшен-гөрелте, ут, куркыныч караңгылык каплады. Яңгыр башлады, әле һаман да коя. Менә тагы иртәгә, өченче көнгә, һич булмаса, бер атнадан, бер айдан соң тагы аязыр, тагы ачылыр, тагы якты, шат көн туар. Килә ачы җилле, салкын яңгырлы көз көннәре... Аннан соң каты, рәхимсез кыш килеп, хәят нурын сүндерә, дөньяны карга күмә, салкыны белән йөрәкләргә үтә. Бу вакыт адәмнәр дөньяга, табигатькә ләгънәт укып, җаннарын кая куярга белмиләр. Ләкин бу хәл мәңге булмый. Озакламый тагы яз килә, тагы матурлык, яктылык туып, кояш иркәләп карый башлый. Тагы сулар ага, кырлар яшәрә, тагы сандугач сайрый. Дөнья тагы шатлана, мәсгуд була. Шулай итеп табигатьтә ямь белән тәм алышынып тора; алар, дөрест, бетәләр, ләкин мәңгегә түгел, вакытлы гына бетәләр, тагы килеп, үзләрен ныграк хис кылдыру өчен генә бетәләр. Ә бездә, адәмнәрнең хәятында, алай түгел. Безнең хәятыбызда «яз» кыска — ул ялтыраган яшен кебек кенә килеп кичә торган мәхәббәтле яшьлек дәвереннән гыйбарәт. Ул үтә дә, куркыныч кара төн булган усал кыш килә. Ләкин ул табигатьтәге кебек вакытлы түгел, ул мәңге, ул кабергәчә. Хәятымызның кояшы бер баеса, янәдән чыкмый, аннан соң син авыр, тәмсез караңгылыкта яшәргә каласың. Менә бервакыт минем көннәрем аяз, күгемнең нәкъ уртасында торып кояш көлә, сандугач сайрый, һәр эш күңелчә булып, сәгадәтнең иге-чиге булмый, — шул дәрәҗә ки, дөньяга китергән тәңреңә сәҗдәдән торасың килми иде...

Язмышның явыз, куәтле, кызганычсыз дулкыны сукты да, һәрнәрсә

---

*1911 елгы басмада *йөрәгеңне яра* сүзләре урынына *җаныңны кырыкка яра* сүзләре килә.

бердәнбер алышынып, яз — соңы килмәс усал кышка, хәятымның көне ниһаясез төнгә әйләнде. Шул төн, шул дәһшәтле караңгы кыш китеп, кояшлы һәм аяз булган яз килер дә, мин тагы үземнең бәхетемә, идеалыма таба атлармын; мин тагы үземнең хәят күгендә көлеп торган кояшны күреп, сандугач сайравын ишетермен дип уйлый алмыйм. Юк, булмас; алда, киләчәктә ни булачагы хәзер күз алдымда. Алгы көндә ничек булуымны хыялым ирексез эшли: балагы чыккан, иске җилән киеп, үзе ышанмаган җәннәткә халыкны өнди торган бер мулла; бер көтү бала; мәет, фидия... Аннан соң караңгы кабер, каберең өстенә яңлыш язулы бер соры таш![*]

Ни дияргә, рухны каплаган тын әрнүне ни дип тәгъбир кылырга белмим. Зиһенемә шагыйремезнең, заманында ятлап та, әллә качан оныткан бер шигыре килә:

Караңгы һәм дә таңы ерак, —
Уты сүнгән җәһәннәм минем төн.[3+]

Шагыйрь үзенең төнен «таңы ерак» ди. Димәк, ниһаясез түгел, качан да булса бер таң ата; димәк, алда бер өмит бар. Әмма миндә алай түгел; гомерем, кояшын, язын югалтып, кара төнгә әйләнгән дә, ул төннең таңы ерак кына түгел, бер дә юк; ул төн мәңге, мәңге. Мин моның болай булуын хәзер бөтен рухым белән хис итәм; «аңлыйм, беләм» түгел; җаным, эчем белән сизенәм. Алда хәят юк; ул сүнгән, анда тик гомер генә — язын, кояшын югалтып, тын, куркыныч кара төнгә әйләнгән гомер генә бар. Аны «киләчәк көн» дип атыйлар. Ул мине көтә. Мин дә, үзем теләмичә, шуның кара һәм караңгылыгыны белә торып, шунарга барырга мәҗбүрмен. Шул мәҗбүриятнең хәзердә хис кылдырган «ужас»ын тәгъбир кылырга, ул «киләчәк көн»нең хәзерге, тик хәзерге секундта рухыма биргән зәһәрле салкынын аңлатырга — «уты сүнгән җәһәннәм» ул диюдән башка бер сүз дә таба алмыйм һәм юктыр да. Араларындагы мөнәсәбәтне белмим, ачык күргәзә дә алмыйм, ләкин ни өчендер аны шулай дип әйтәсем килә, шуны эчке бер куәт тели, хәзер шуны бик нык хис итәм: ул — ул — уты сүнгән җәһәннәм — мине көтә.

Яңгыр туктады. Баягы тынлык бетеп, болытлар катлаулана, җил тагы сызгыра башлады. Тәрәзәм каршысындагы караңгы бакчада яфраклар шыбырдый, каравылчы да кара төнне ярып никтер шакылдарга тотынды. Йөрәк ашкынып, яңа бер куәт белән сикерә, ни өчендер баягыча баягы урында тын гына утырасы килми... Ходаем, тагы ниләр генә булыр икән?.. Үзеңнән-үзең риза булмаучылык ниһаясенә җитә, рухны бөтенләй нindидер

---

[*]1911 елгы вариантта бу ике җөмләнең бирелеше түбәндәгечә: *Алгы көндә ничек булуымны хыялым ирексез эшли: балагы чыккан, иске җилән кигән бер мулла; бер көтү бала; мәет, фидия...кабер...*

бер коры сызлау, нинди зәһәрле бер әрнү, ачы бер изтираб каплый.* Уйлыйм, тәмуг, дим, юктыр, булса — минем хәзерге минутым үзе тәмугдыр.

Минем уем нәкъ шул йиргә җиткән чагында куәтле бер яшен яшьни, бөтен дөньяны гаҗиб[1] бер яктылык ала; вә шул яктылыкның караңгылык белән аралашып киткән актык секундында хыялымда өзгеч бер күренеш ялтырап китә: гүя мин гарештән, нурдан егылып, ниһаясез караңгы төнгә, түбәнгә, коточкыч астка киткәнмен дә, шуны аңлап, кабаттан өсткә чыгарга талпынам, ләкин куәт юк, канат кисек булганга, кире йөзтүбән, әүвәлгедән дә төпкәрәк китәм, имеш...

Мин шул күренештән айнып та җитә алмадым, теге якта бала җылаганы ишетелде, хатыным йокы арасыннан тагы:

— Садыйк, Садыйк, җә инде, ят инде!.. Бу ниткән эш!! Илаһым!.. — дип сукрана башлады.

Тагы бер кат яшен яшьнәде дә коеп яңгыр яварга тотынды.

Мин дә, авырып, ватылып, гәүдәмне чак өстерәп, хатыным янына барып егылдым...*

---

*1911 елгы басмада бу җөмлә түбәндәгечә: *Үзеңнән-үзең риза булмаучылык ниһаясенә йитә бугай, рухны бөтенләй икенче төрле булган тын вә фигаль бер әрнү вә ачы бер изтыйраб каплый.*

[1] *Гаҗиб* — искиткеч.

*1911 елгы вариантта бу җөмлә түбәндәгечә: *Мин дә хатыным янына киттем.* Аннары күпнокталардан соң: *Хикәя шул йирдә киселде. Без дә бер-беремезгә сүзсез генә кул бирешеп, таралыштык.* – җөмләләре килә.